**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№ 231** **от 05.08.2020 г.**

**"Физик затлар мөлкәтенә салым турында"**
**2014 елның 13 ноябрендәге 201 номерлы**
**Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге**
**Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 2014 елның 13 ноябрендәге 201 номерлы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 10 сентябрендәге 252 номерлы, 2018 елның 24 октябрендәге 156 номерлы, 2019 елның 16 мартбрендәге 178 номерлы, 2019 елның 12 декабрбрендәге 209 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 1 пунктчасының өченче абзацында «бирелгән» сүзен һәм «дача» сүзен төшереп калдырырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,Александр Бистәсе**
**авыл җирлеге башлыгы** **Л.Г. Варганова**